# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Халыкның санитария-эпидемия иминлеге турында

Әлеге Закон халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итүгә һәм гражданнарның сәламәтлеген саклауга булган, сәламәт әйләнә-тирә табигать мохитенә булган конституциячел хокукларын реализацияләүгә юнәлдерелә.

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр

Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

кешенең яшәү тирәлеге (алга таба - яшәү тирәлеге) - кешенең тормыш эшчәнлеге шартларын билгеләүче әйләнә-тирә (табигать һәм ясалма) мохит объектларының, күренешләренең һәм факторларының бергәлеге ул;

яшәү тирәлеге факторлары - кешегә һәм (яисә) киләчәк буыннар сәламәтлеге торышына йогынты ясаучы яисә йогынты ясарлык биологик (вирус, бактериаль, паразитар һәм башка), химик, физик (шау-шу, вибрация, ультратавыш, инфратавыш, җылылык, ионлаштырылган, ионлаштырылмаган һәм башка төрле нурланыш), социаль (туклану, су белән тәэмин ителеш, көнкүреш, хезмәт һәм ял шартлары) һәм яшәү тирәлеген тәшкил итүче бүтән төрле факторлары ул;

санитария-эпидемиология вәзгыяте - билгеле бер вакыт эчендә билгеле бер территориядә халык сәламәтлегенең һәм яшәү тирәлегенең торышы ул;

халыкның санитария-эпидемия иминлеге - яшәү тирәлегенең билгеле бер торышы ул, бу чакта кешегә зарарлы факторларның йогынтысы тулысынча кими яисә бөтенләй юкка чыга, халыкның

тормыш эшчәнлеге өчен уңай шартлар булдырыла һәм җәмәгатьчелек сәламәтлегенең яхшыру тенденциясе сизелә;

дәүләт санитария-эпидемиология нормалаштыруы - дәүләт санитария-эпидемиология кагыйдәләрен һәм нормативларын нигезләүне, урнаштыруны, раслауны, теркәүне һәм бастырып чыгаруны үз эченә алучы эшчәнлек ул;

дәүләт санитария-эпидемиология кагыйдәләре һәм нормативлары (алга таба - санитар кагыйдәләр) - үтәлмәүләре аркасында кеше гомеренә яисә сәламәтлегенә янарлык, шулай ук авырулар килеп чыгу һәм таралу белән янарлык, санитар-эпидемиологик таләпләр (шул исәптән кешенең яшәү тирәлеге факторларының иминлеге һәм (яисә) зарарсызлыгы критерийлары, гигиеник һәм башка төрле нормативлар) урнаштыручы норматив-хокукый актлар ул;

социаль-гигиеник мониторинг - халык сәламәтлеген һәм яшәү тирәлеге торышын күзәтүләрнең, аларны анализлауның, бәяләүнең һәм фаразлауның, шулай ук халык сәламәтлеге торышы белән яшәү тирәлеге факторларының йогынтысы арасындагы сәбәп - максат бәйланышларын билгеләүнең дәүләт системасы ул;

дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеге - халыкның сәламәтлеген һәм яшәү тирәлеген саклау максатларында халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын бозуларны булдырмый калу, ачыклау һәм кисәтү эшчәнлеге ул;

туклануның физиологик нормалары - кеше сәламәтлегенең оптимальлеген тәэмин итүче азык-төлек матдәләрен һәм энергияне куллануның билгеләнгән зурлыклары ул;

эпидемиягә каршы санитар (профилактик) гамәлләр - яшәү тирәлеге факторларының кешегә зарарлы йогынтысын бетерүгә яисә киметүгә юнәлдерелгән, йогышлы авырулар һәм йогышлы булмаган массакүләм авырулар (агуланулар) барлыкка килүне һәм таралуны кисәтүгә һәм аларны ликвидацияләүгә юнәлдерелгән оештыру, административ, инженер-техник, медик-санитар, ветеринар һәм башка төрле гамәлләр ул;

санитария-эпидемиология бәяләмәсе - яшәү тирәлеге факторларының, хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка төрле эшчәнлекнең, продукциянең, эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең, шулай ук норматив актлар проектларының, объектларны төзү проектларының, эксплуатация документларының санитар кагыйдәләргә туры килүен (туры килмәвен) таныклаучы документ ул.

<u>2 статья.</u> Татарстан Республикасында халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итүнең төп юнәлешләре

Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү эшчәнлеге түбәндәге төп юнәлешләр буенча башкарыла:

халыкның сәламәтлеген ныгытуга, авыруларны профилактикалауга, кешенең яшәү тирәлеген сәламәтләндерүгә һәм аның тормыш эшчәнлеге өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән дәүләт программаларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру;

санитария-эпидемиология күзәтчелеген тормышка ашыру;

дәүләт санитария-эпидемиология нормалаштыруы;

кеше сәламәтлеге өчен куркыныч тудырырлык продукцияне, эшләрне һәм хезмәт күрсәтүләрне сертификацияләү;

кеше сәламәтлеге өчен потенциаль куркыныч булган эшчәнлек төрләрен лицензияләү;

социаль-гигиеник мониторинг уздыру;

эпидемиягә каршы санитар (профилактик) гамәлләр оештыру һәм уздыру;

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә фәнни тикшеренүләр;

санитария-эпидемиология вәзгыяте нигезендә халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү гамәлләрен финанслау;

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы законнары үтәлешендә гражданнарны, индивидуаль эшкуарларны һәм юридик затларны икътисадый кызыксындыруны арттыру;

санитария-эпидемиология вәзгыятенең торышы турында һәм үткәрелүче эпидемиягә каршы санитар (профилактик) гамәлләр турында мәгълүмат системасын үстерү;

халыкны гигиеник тәрбияләү һәм белем бирү.

## 3 статья. Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы законнары

Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы законнары (алга таба - санитар законнар) әлеге Законнан һәм Татарстан Республикасының башка закон актларыннан гыйбарәт була.

## 4 статья. Санитар кагыйдәләр, нормалар һәм гигиеник нормативлар

Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе законнары нигезендә расланган санитар кагыйдәләр (федераль санитар кагыйдәләр) гамәлдә булалар.

Санитария-эпидемиология нормалаштыруының кайбер мәсьәләләре буенча федераль санитар кагыйдәләр булмаганда, шулай ук федераль санитар кагыйдәләрдә билгеләнгән таләпләрдән катырак өстәмә санитария-эпидемиология таләпләрен кертү кирәк булганда, гигиеник, эпидемиологик һәм экологик вәзгыятькә һәм халыкның

сәламәтлеге торышына карап, Татарстан Республикасы территориясендә республика санитар кагыйдәләре кертелергә мөмкин.

Гражданнарның, индивидуаль эшкуарларның һәм юридик затларның санитар кагыйдәләрне үтәүләре мәҗбүри.

Санитар кагыйдәләр законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлергә һәм рәсми басылып чыгарылырга тиеш.

## II бүлек. Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, җирле үзидарә органнарының компетенциясе

**5 статья.** Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы компетенциясе

Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен билгеләү һәм гамәлгә ашыру;

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен билгеләү һәм гамәлгә ашыру;

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

санитар законнарның үтәлешен тикшереп тору;

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә мөһим дәүләт программаларын раслау;

санитария-эпидемиология вәзгыятен яхшырту, авыруларны профилактикалау, хезмәт шартларын яхшырту, халыкны гигиеник тәрбияләү һәм белем бирү буенча гражданнарның, индивидуаль эшкуарларның һәм юридик затларның эшчәнлеген икътисадый хуплау.

**6 статья.** Халыкның санитария-эпидемия иминлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты компетенциясе

Халыкның санитария-эпидемия иминлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә максатчыл дәүләт программаларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру;

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы хезмәте турындагы нигезләмәне раслау;

Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте турындагы нигезләмәләрне раслау, шулай ук аның нәтиҗәле эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы әзерләгән республика санитар кагыйдәләрен гамәлгә кертү, яңадан карап чыгу һәм юкка чыгару;

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча халыкара хезмәттәшлек;

законнар нигезендә башка төрле вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

**7 статья.** Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы компетенциясе

Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы Татарстан Республикасында санитария-эпидемиология дәүләт күзәтчелеген башкару вәкаләте тапшырылган дәүләт идарәсе органы була.

Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасының санитария-эпидемиология дәүләт хезмәте эшчәнлегенә житәкчелек итү;

эпидемиягә каршы санитар (профилактик) гамәлләрне оештыру һәм уздыру;

санитария-эпидемиология вәзгыятен тикшереп тору;

законнар нигезендә башка төрле вәкаләтләр башкару.

**8 статья.** Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә халык депутатларының жирле Советлары компетенциясе

Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә халык депутатларының жирле Советлары компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

санитар законнар үтәлешен тикшереп тору;

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлешендә жирле бюджеттан сәламәтлек саклауга чыгымнарның статьяларын карау һәм раслау;

эпидемиягә каршы санитар (профилактик) гамәлләрне уздыру өчен билгеләнгән бюджеттан тыш максатчыл фондларны төзү турындагы карарларны кабул итү;

әйләнә-тирә мохитнең кешегә уңайсыз йогынтысын кисәтү һәм бетерү, авыруларны профилактикалау, кешеләрнең хезмәт, көнкүреш

һәм тормыш эшчәнлеге шартларын яхшырту буенча гражданнарның, индивидуаль эшкуарларның һәм юридик затларның эшчәнлеген икътисадый хуплау;

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә жирле программаларны раслау.

9 статья. Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә районнарның, шәһәрләрнең, шәһәрләрдәге районнарның жирле администрацияләре компетенциясе

Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә районнарның, шәһәрләрнең, шәһәрләрдәге районнарның жирле администрацияләре компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне тикшереп тору;

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә жирле программаларны әзерләү һәм гамәлгә ашыру;

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча гражданнарның, индивидуаль эшкуарларның һәм юридик затларның эшчәнлеген жайга салу;

үз ведомствосындагы территориядә эпидемиягә каршы санитар (профилактик) гамәлләрне оештыру һәм уздыру.

10 статья. Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә жирле үзидарә органнары компетенциясе

Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә жирле үзидарә органнары законнар нигезендә үзләренә тапшырылган вәкаләтләр чикләрендә эшчәнлек алып баралар.

## III бүлек. Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә гражданнарның, индивидуаль эшкуарларның һәм юридик затларның хокуклары һәм бурычлары

11 статья. Гражданнарның хокуклары

Татарстан Республикасы гражданнары түбәндәге хокукларга ия:

кешегә зарарлы йогынты ясамаслык факторлары булган уңайлы яшәү тирәлегенә;

башка гражданнар, индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар санитар законнарны бозулары аркасында, шулай ук эпидемиягә каршы санитар (профилактик) гамәлләр башкарганда үзләренең гомеренә,

сәламәтлегенә яисә мөлкәтенә китерелгән зыянны законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерү;

санитария-эпидемиология вәзгыяте турында, уңайсыз факторлар һәм аларның яшәү тирәлегенә (торакка, уку, эш, ял итү урынына) йогынты ясау дәрәҗәләре турында, азык-төлек продуктларының, житештерү-техник продукциянең, шәхси (көнкүреш) ихтыяжлар өчен товарларның сыйфаты һәм иминлеге турында, кеше өчен куркыныч тудырырлык башкарылучы эшләр һәм күрсәтелүче хезмәтләр турындагы мәгълүматларны дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарыннан, жирле үзидарә органнарыннан, халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органнарыннан сорату һәм алу;

санитар кагыйдәләр үтәлешен гражданнарның жәмәгать берләшмәләре аша аларның уставлары нигезендә тикшереп тору, тәкъдимнәр кертү, халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән карарларны дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары әзерләгәндә, фикер алышуларда катнашу.

Татарстан Республикасы территориясендәге чит ил гражданнарына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре нигезендә сәламәтлек саклауга һәм уңайлы яшәү тирәлегенә хокук гарантияләнә.

<u>12 статья.</u> Индивидуаль эшкуарларның һәм юридик затларның хокуклары

Индивидуаль эшкуарларның һәм юридик затларның хокуклары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

санитария-эпидемиология вәзгыяте, гамәлдәге санитар кагыйдәләр турында мәгълүматны дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарыннан, жирле үзидарә органнарыннан, Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте органнарыннан һәм учреждениеләреннән законнар нигезендә соратудан һәм алудан;

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән программаларны әзерләүдә катнашудан;

гражданнарның, индивидуаль эшкуарларның һәм юридик затларның санитар законнарның таләпләрен бозулары аркасында, шулай ук эпидемиягә каршы санитар (профилактик) гамәлләр уздырганда аларның мөлкәтенә китерелгән зыянны законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерүдән.

<u>13 статья.</u> Гражданнарның бурычлары

Гражданнар түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

халыкның санитария-эпидемия иминлеге турындагы законнарның таләпләрен, шулай ук санитария-эпидемиология күзәтчелеген

башкаручы урындагы затларның карарларын, күрсәтмәләрен һәм санитария-эпидемиология бәяләмәләрен үтәргә;

үз балаларының сәламәтлеге һәм гигиеник тәрбиясе турында кайгыртырга;

башка гражданнарның сәламәтлегенә һәм уңайлы яшәү тирәлегенә хокукларын бозуга китерерлек гамәлләр кылмаска.

## 14 статья. Индивидуаль эшкуарларның һәм юридик затларның бурычлары

Индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

санитар законнарның таләпләрен, шулай ук санитария-эпидемиология күзәтчелеген башкаручы урындагы затларның карарларын, күрсәтмәләрен һәм санитария-эпидемиология бәяләмәләрен үтәргә;

эпидемиягә каршы санитар (профилактик) гамәлләрне әзерләргә һәм үткәрергә;

дәүләт стандартларына һәм санитар кагыйдәләргә туры килерлек продукция житештерүне һәм реализацияләүне тәэмин итәргә;

гамәлгә ашырылучы эшчәнлеккә караган санитар кагыйдәләрнең рәсми басмаларын үзендә булдырырга;

халыкка, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнарына, җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте органнарына һәм учреждениеләренә санитария-эпидемиология вәзгыятенә янарлык һәлакәтле хәлләр турында үз вакытында хәбәр итәргә;

хезмәткәрләргә гигиена белеме бирергә.

# IV бүлек. Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү буенча гомуми таләпләр

## 15 статья. Районнарны һәм республика буйсынуындагы шәһәрләрне планлаштыруга һәм төзүгә карата таләпләр

Районнарны һәм республика буйсынуындагы шәһәрләрне планлаштырганда һәм төзегәндә түбәндәгеләр күздә тотылырга тиеш:

аларның территорияләрен комплекслы төзекләндерү;

халыкның гомере һәм сәламәтлеге өчен уңай шартлар тудыру;

кешегә, шулай ук аның тормышы һәм эшчәнлеге шартларына яшәү тирәлеге факторларының уңайсыз йогынтысын кисәтү һәм бетерү гамәлләре.

Проектлаштыру нормаларын, районны планлаштыру проектларын, шәһәрләрнең генераль планнарын, районнарны һәм республика

буйсынуындагы шәһәрләрне планлаштыру һәм төзү проектларын әзерләгәндә, граждан, сәнәга һәм авыл хуҗалыгы объектларын урнаштыру мәсьәләләрен хәл иткәндә, төзелеш өчен җир кишәрлекләре сайлаганда, шулай ук объектларны (эшләтеп җибәрү комплексларын), корылмаларны, һәм инженер коммуникацияләрен проектлаштырганда, төзегәндә, реконструкцияләгәндә һәм техник яктан яңадан җиһазландырганда санитар законнарның таләпләре үтәлергә тиеш.

Төзелеш өчен җир кишәрлекләре бирү, проектлаштыру нормаларын, төзелешнең, реконструкцияләүнең, объектларны техник яктан яңадан җиһазлауның, районнарны һәм республика буйсынуындагы шәһәрләрне планлаштыруның һәм төзүнең проект документларын раслау, төзелгән, реконструкцияләнгән торак йортларны һәм мәдәни-көнкүреш, торак-коммуналь, сәнәга, транспорт биналарын һәм корылмаларын, башка объектларны (эшләтеп җибәрү комплексларын) һәм төзелмәләрне файдалануга тапшыру санитар законнарның таләпләре үтәлешен таныклаучы санитария-эпидемиология бәяләмәләре булганда гына гамәлгә ашырыла.

Объектларны проектлаштыру һәм төзү эшләрен үтәү өчен, аларны финанслау һәм (яисә) кредитлаштыру өчен җаваплы гражданнар, индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар, санитар законнарны бозу ачыкланган яисә аларны үти алмау мөмкинлеге булган очракта, күрсәтелгән эшләрне башкаруны, аларны финанслауны һәм (яисә) кредитлаштыруны туктатып торырга йә бөтенләй туктатырга тиешләр.

<u>16 статья.</u> Житештерү-техник билгеләнештәге продукциягә, гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары товарларына һәм аларны әзерләү технологияләренә карата таләпләр

Җитештерүе, транспортта ташуы, саклавы һәм куллануы кешенең турыдан-туры катнашуын таләп итә торган житештерү-техник билгеләнештәге продукция, шулай ук гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары товарлары (алга таба - продукция) санитар нормаларга һәм кагыйдәләргә туры килергә тиеш.

Беренче мәртәбә әзерләнгән яисә житештерүгә кертелүче продукцияне әзерләү, куллану (файдалану), продукцияне житештерүнең яңа технологик процесслары бары тик аларның санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитария-эпидемиология бәяләмәсе бирелгәннән соң гына рөхсәт ителә.

Продукция әзерләүче, житештерүче, транспортлаучы, сатып алучы, саклаучы һәм реализацияләүче гражданнар, индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар, бу продукциянең санитар кагыйдәләр таләпләренә туры килмәве билгеләнгән очракта, мондый эшчәнлекне туктатып торырга, реализацияләүдән алырга һәм кешегә зарар китерүне

булдырмас өчен продукцияне куллану (файдалану) чараларын күрергә яисә аны бөтенләй юк итәргә тиешләр.

**17 статья.** Кеше өчен потенциаль куркыныч химик һәм биологик матдәләргә таләпләр

Кеше өчен потенциаль куркыныч химик һәм биологик матдәләрне житештерү, саклау, транспортлау, реализацияләү һәм куллану (файдалану) бары тик алар законнар нигезендә дәүләт теркәве узганнан соң гына рөхсәт ителә.

**18 статья.** Татарстан Республикасы территориясенә кертелүче продукциягә карата таләпләр

Гражданнар, индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы территориясенә кертелүче, сәнәгадә, авыл хужалыгында, граждан төзелешендә, транспортта куллану өчен билгеләнгән, куллану (файдалану) барышында кешенең турыдан-туры катнашуын таләп итә торган һәм (яисә) халыкка сату өчен билгеләнгән продукция, азык-төлек продуктларын һәм азык-төлек чималын да кертеп, кешеләр гомере һәм сәламәтлеге, яшәү тирәлеге өчен хәвефсез булырга тиеш.

Продукциянең санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитария-эпидемиология бәяләмәсе булганда гына, ул Татарстан Республикасы территориясенә кертелә.

**19 статья.** Азык-төлек чималына, ашамлык продуктларына, аларга орынып торган материалларга һәм әйберләргә, шулай ук аларны әзерләү технологияләренә карата таләпләр

Ашамлык продуктлары кешенең физик ихтыяжларын канәгатьләндерергә һәм аның сәламәтлегенә зарарлы йогынты ясамаска тиеш. Азык-төлек чималы, ашамлык продуктлары, алар белән бәйләнештә булучы материаллар һәм әйберләр аларны әзерләү, саклау, транспортлау һәм халыкка реализацияләү процессында санитар кагыйдәләр таләпләренә туры килергә тиеш.

Ашамлык продуктларын житештергәндә ашамлык өстәлмәләре, билгеләнгән тәртиптә куллану өчен рөхсәт ителгән һәм аларга орынып торган материаллар һәм әйберләр кулланылырга мөмкин.

Яңа төр (беренче мәртәбә әзерләнгән һәм житештерүгә кертелгән) азык-төлек чималын, ашамлык продуктларын, ашамлык өстәлмәләрен, аларга орынып торган материалларны һәм әйберләрне житештерү, куллану (файдалану) һәм халыкка реализацияләү, шулай ук аларны житештерүнең яңа технологик процессларын һәм технологик жиһазларны гамәлгә кертү аларның санитар кагыйдәләргә туры килүе

турында уңай санитария-эпидемиология бәяләмәсен алганнан соң гына рөхсәт ителә.

Азык-төлек чималын һәм ашамлык продуктларын җитештерүне, саклауны, транспортлауны һәм реализацияләүне гамәлгә ашыручы гражданнар, индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар тиешле эшчәнлек төрләре һәм объектлар өчен билгеләнгән санитар кагыйдәләр таләпләрен үтәргә һәм ашамлык продуктларының сыйфатын начарайтуны булдырмау чараларын күрергә тиеш.

Санитар кагыйдәләргә туры килми торган һәм кеше өчен куркыныч тудыручы азык-төлек чималы, ашамлык продуктлары, аларга орынып торган материаллар һәм әйберләр җитештерүдән һәм (яисә) реализацияләүдән кичекмәстән алына.

Җитештерүдән яисә реализацияләүдән алынган азык-төлек чималы, ашамлык продуктлары, аларга орынып торган материаллар һәм әйберләр аларның хуҗалары тарафыннан кешегә зыян килмәслек башка максатларда кулланылырга йә юкка чыгарылырга тиеш.

## 20 статья. Халыкның туклануын оештыруга карата санитар таләпләр

Махсус җиһазландырылган урыннарда (ашханәләрдә, рестораннарда, кафеларда, барларда һәм башкаларда) халыкның туклануын оештырганда, шул исәптән ашамлык һәм эчемлекләр әзерләгәндә, аларны саклаганда һәм халыкка реализацияләгәндә йогышлы авырулар һәм йогышлы булмаган массакүләм авырулар (агуланулар) килеп чыгуын һәм таралуын булдырмас өчен санитар кагыйдәләр үтәлергә тиеш.

Балалар, мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен, югары һәм урта белем уку йортларында, дәвалау-профилактикалау, сәламәтләндерү учреждениеләрендә, социаль яклау учреждениеләрендә туклануны оештырганда, хәрбиләр өчен туклану нормаларын, шулай ук тикшерү изоляторларындагы яисә төзәтү учреждениеләрендә җәза үтүче гражданнарның туклану нормаларын билгеләгәндә туклануның физиологик нормалары катгый үтәлергә тиеш.

Халыкның тормыш дәрәҗәсенең дәүләт тарафыннан гарантияләнүче минималь социаль стандартларын билгеләгәндә туклануның физиологик нормалары да исәпкә алынырга тиеш.

## 21 статья. Халык файдалана торган су объектларына карата таләпләр

Эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү, коену, спорт белән шөгыльләнү, ял итү һәм дәвалану максатларында файдаланылучы су объектлары кешегә зарарлы йогынты ясамаска тиеш. Су объектларыннан файдалану конкрет күрсәтелгән максатлар

өчен су сыйфатының санитар кагыйдәләр таләпләренә туры килүе турында, шулай ук су объектыннан кеше сәламәтлеге өчен хәвефсез файдалану шартлары турында санитария-эпидемиология бәяләмәсе булганда гына рөхсәт ителә.

Районнар һәм республика буйсынуындагы шәһәрләр чикләрендә урнашкан су объектларындагы суның сыйфаты санитар кагыйдәләр таләпләренә туры килергә тиеш.

Су объектларының пычрануын булдырмый калу максатларында халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы белән килештереп, су объектларына зарарлы йогынтыларының иң чик мөмкин нормативлары законнар нигезендә билгеләнә.

Эчәр өчен, хуҗалык-көнкүрешне су белән тәэмин итү өчен һәм дәвалау максатларында файдаланылучы су объектлары округларының һәм санитар саклау зоналарының проектлары, аларның санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитария-эпидемиология бәяләмәсе булганда, дәүләт идарәсе органнары тарафыннан раслана.

Су объектлары халык сәламәтлегенә куркыныч тудырган очракларда дәүләт идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары, индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар су объектларыннан файдалануны чикләүгә, туктатып торута яисә бөтенләй тыюга юнәлдерелгән чараларны үз вәкаләтләре нигезендә күрергә тиеш.

**22 статья.** Халыкны эчәр сулар белән тәэмин итүгә карата таләпләр

Республика буйсынуындагы шәһәрләрнең, шәһәрләрнең һәм авылларның халкы санитар кагыйдәләр таләпләренә җавап бирерлек эчәр сулар белән кешенең физиологик һәм көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек күләмдә тәэмин ителергә тиеш.

**23 статья.** Республика буйсынуындагы шәһәрләрнең, шәһәрләрнең һәм авылларның атмосфера һавасы сыйфатына, эш зоналары һавасының һәм кешеләрнең даими, вакытлы булу урыннары һавасының сыйфатына карата таләпләр

Республика буйсынуындагы шәһәрләрнең, шәһәрләрнең һәм авылларның, сәнәгать предприятиеләре территорияләренең атмосфера һавасы сыйфаты, эш зоналары, җитештерү һәм башка биналар һавасы, кешеләрнең даими һәм вакытлы булу урыннарындагы һава санитар кагыйдәләр таләпләренә туры килергә һәм предприятиеләр җитештерә торган продукциянең сыйфатына һәм кешегә тискәре йогынты ясамаска тиеш.

Атмосфера һавасына чыгарылучы зарарлы матдәләрнең иң чик мөмкин нормативлары билгеләнгәндә һәм расланганда санитария-

эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы белән килештерелергә тиеш.

24 статья. Туфракны санитар саклау, республика буйсынуындагы шәһәрләрнең, шәһәрләрнең һәм авылларның территорияләрен һәм җитештерү территорияләрен тотуга, җитештерү һәм куллану калдыкларын җыюга, эшкәртүгә, зарарсызландыруга, файдалы эшкә тотуга һәм күмүгә карата таләпләр

Республика буйсынуындагы шәһәрләр, шәһәрләр һәм авыллар туфрагында һәм авыл хуҗалыгының уңдырышлы җирләре туфрагында кеше өчен потенциаль куркыныч химик һәм биологик матдәләрнең, биологик һәм микробиологик организмнарның булуы, шулай ук радиация фоны дәрәҗәсе санитар кагыйдәләрдә билгеләнгән нормативлардан артмаска тиеш.

Республика буйсынуындагы шәһәрләр, шәһәрләр һәм авыллар территорияләрен тотуны тәэмин итү тәртибе һәм шартлары, күрсәтелгән тәртиптә шартларның санитар кагыйдәләр таләпләренә туры килүе турында санитария-эпидемиология бәяләмәсе булса гына, дәүләт хакимияте һәм идарәсе җирле органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

Җитештерү һәм куллану калдыклары законнарда билгеләнгән тәртиптә җыелырга, эшкәртелергә, зарарсызландырылырга, күмелергә һәм файдалы эшкә тотылырга тиеш.

Радиоактив пычрануы санитар кагыйдәләрдә билгеләнгән дәрәҗәдән артып киткән калдыклар законнар нигезендә эшкәртелергә, зарарсызландырылырга, файдалы эшкә тотылырга һәм күмелергә тиеш.

25 статья. Торак биналарның торышына карата таләпләр

Торак биналар, анда күпме вакыт яшәүгә карамастан, яшәү өчен имин һәм зарарсыз шартлар тәэмин итү максатларында, мәйданы, планлаштырылуы, яктыртылуы, кояш төшүе, микроклиматы, һава алмашынуы, шау-шу, вибрация, ионлаштырылган һәм ионлаштырылмаган нурланыш дәрәҗәсе буенча санитар кагыйдәләргә туры килергә тиеш.

Санитар кагыйдәләргә җавап бирми торган торак биналарына кешеләрне урнаштыру, шулай ук даими һәм вакытлы яшәү өчен гражданнарга торак булмаган биналар бирү рөхсәт ителми.

Торак биналарны тоту санитар кагыйдәләргә җавап бирергә тиеш.

26 статья. Житештерү биналарыннан, иҗтимагый биналардан, төзелмәләрдән, корылмалардан, җайланмалардан һәм транспорттан файдаланганда таләпләр

Житештерү биналарыннан, иҗтимагый биналардан һәм урыннардан, төзелмәләрдән, корылмалардан, җайланмалардан һәм транспорттан файдаланганда кеше өчен уңайлы хезмәт, көнкүреш һәм ял шартлары тәэмин ителергә, шулай ук эпидемиягә каршы санитар (профилактик) чаралар күрелергә тиеш.

Индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар санитар кагыйдәләр таләпләре бозылган һәм шушы эшчәнлекне гамәлгә ашыру эшләрне башкару һәм хезмәт күрсәтүләр кеше өчен куркыныч булган һәм санитар кагыйдәләр таләпләрен бозган очракларда, үзләренең эшчәнлеген тулысынча яисә аерым цехларның, участокларның эшен, биналардан, корылмалардан, җайланмалардан, транспорттан файдалануны, аерым төр эшләрне башкаруны һәм (яисә) хезмәт күрсәтүләрне туктатып торырга йә бөтенләй туктатырга тиеш.

27 статья. Хезмәт шартларына карата таләпләр

Хезмәт шартлары, эш урыны һәм хезмәт процессы кешегә зарарлы йогынты ясамаска тиеш. Кеше өчен хәвефсез хезмәт шартлары тәэмин итүгә карата таләпләр санитар кагыйдәләр һәм бүтән төрле норматив хокукый актлар белән билгеләнә.

Индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар кеше өчен хәвефсез хезмәт шартлары тудыруны тәэмин итү буенча һәм, хезмәт шартларына бәйле травмаларны, профессиональ авыруларны, йогышлы авыруларны һәм йогышлы булмаган массакүләм авыруларны (агулануларны) кисәтү максатларында, җитештерү процессларына һәм технологик җайланмаларга карата, эш урыннарын оештыруга, эшләүчеләрне күмәк һәм индивидуаль яклау чаралары белән тәэмин итүгә, хезмәт һәм ял итү режимына һәм эшләүчеләргә көнкүреш хезмәте күрсәтүгә карата санитар кагыйдәләр һәм башка законнарның таләпләрен үтәү буенча эпидемиягә каршы санитар (профилактик) гамәлләрне башкарырга тиешләр.

28 статья. Биологик матдәләр, биологик һәм микробиологик организмнар һәм аларның токсиннары белән эшләү шартларына карата таләпләр

Биологик матдәләр, микробиологик организмнар һәм аларның токсиннары белән, шул исәптән кешедә йогышлы авырулар кузгатучы матдәләр белән эшләр башкару, шулай ук геннар инженерлыгы өлкәсендәге эшләр хезмәт шартларының санитар кагыйдәләр

таләпләренә туры килүе турында санитария-эпидемиология бәяләмәсе булганда гына рөхсәт ителә.

29 статья. Кешегә йогынты ясаучы физик факторларның чыганаклары белән эшләү шартларына карата таләпләр

Кешегә йогынты ясаучы физик факторларның чыганаклары (шау-шу, вибрация, ультратавыш, инфратавыш йогынтылары, җылылык, ионлаштырылган, ионлаштырылмаган һәм башка төрле нурланыш) булган машиналар, механизмнар, җайланмалар, җиһазлар, аппаратлар белән эшләү шартлары санитар кагыйдәләр таләпләренә туры килергә тиеш.

Радиоактив матдәләрне, материалларны һәм калдыкларны җитештерү, саклау, транспортлау, куллану һәм күмү, физик факторларның чыганаклары булган машиналарны, механизмнарны, җайланмаларны, җиһазларны һәм аппаратларны куллану бары тик башкарылучы эш шартларының санитар кагыйдәләр таләпләренә туры килүен раслаучы санитария-эпидемиология бәяләмәләре булганда гына рөхсәт ителә.

Ионлаштырылган нурланыш чыганаклары белән эшләүнең хәвефсезлеген һәм халыкның радиация иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләр радиация иминлеге турындагы законнар белән җайга салына.

30 статья. Мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыруга карата таләпләр

Гомуми белем учреждениеләрендә санитар законнарның таләпләре нигезендә балаларның сәламәтлеген саклау һәм авыруларны профилактикалау чаралары, шул исәптән аларның туклануын оештыру чаралары күрелергә тиеш.

Тәрбия, белем бирү, һөнәри әзерлек программалары, методикалары, режимнары, дәреслекләр һәм бүтән төрле басма продукция, уку-укыту җиһазлары, техник, аудиовизуаль һәм бүтән төрле чаралар бары тик аларның санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитария-эпидемиология бәяләмәләре булганда гына файдалануга кертелә.

## V бүлек. Эпидемиягә каршы санитар (профилактик) чаралар

31 статья. Эпидемиягә каршы санитар (профилактик) чаралар оештыру һәм уздыру

Йогышлы авырулар һәм йогышлы булмаган массакүләм авырулар (агуланулар) барлыкка килүне һәм таралуны кисәтү

максатларында санитар законнарда каралган эпидемиягә каршы санитар (профилактик) гамәлләр үз вакытында һәм тулы күләмдә башкарылырга тиеш.

Татарстан Республикасы территориясенә кеше өчен аеруча куркыныч тудыручы йогышлы авыруларны кертүне, аларның барлыкка килүен һәм таралуын булдырмау өчен Татарстан Республикасы территориясен санитар саклау оештырыла.

Территорияне санитар саклау гамәлләрен уздыруны таләп итүче йогышлы авыруларның исемлеге халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы тәкъдиме буенча һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

Татарстан Республикасы территориясен санитар саклауны оештыру, аны тормышка ашыру гамәлләре, аларны уздыру тәртибе һәм шартлары санитар законнар һәм бүтән законнар белән регламентлаштырыла.

Йогышлы авырулар һәм йогышлы булмаган массакүләм авырулар (агуланулар) барлыкка килү һәм таралу куркынычы килеп чыккан очракта, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты һәм районнарның, шәһәрләрнең һәм шәһәрләрдәге районнарның администрацияләре законнарда билгеләнгән тәртиптә үз карарлары белән карантин кертә яисә халык өчен бу авыруларның таралуын булдырмый калуга һәм аларны бетерүгә юнәлдерелгән аерым шартлар һәм яшәү режимнары күз алдында тотучы чикләү гамәлләре билгели алалар.

Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы карантин яисә чикләү гамәлләре яки башка махсус режимнар кертү (аларны юкка чыгару) буенча тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына кертә.

Массакүләм авыруларны кисәтү һәм бетерү буенча гражданнарның, индивидуаль эшкуарларның һәм юридик затларның эшчәнлегенә оператив җитәкчелек итү һәм аларны җайга салу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршында һәм шәһәрләрнең, районнарның, шәһәрләрдәге районнарның администрацияләре каршында эпидемиягә каршы санитар комиссияләр төзелә.

Йогышлы авырулар белән авыручылар, шундый авырулар белән чирләүдә шик тудыручы затлар һәм йогышлы авырулар белән аралашкан затлар лаборатор тикшеренү узарга һәм медицина күзәтүе астына яисә дәвалануга алынырга тиешләр, әгәр алар әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган булсалар - катгый рәвештә госпитальләштерелергә яисә изоляцияләнергә (карантинга куелырга) тиешләр.

Йогышлы авырулар кузгатучыларны үзләрендә йөртүче затлар дәваланырга тиеш, әгәр алар үзләре шөгыльләнүче җитештерү

үзенчәлекләренә яисә башкаручы эшләре үзенчәлекләренә бәйле рәвештә йогышлы авыруларны таратучы чыганакка әйләнсәләр, йогышлы авыруларны тарату куркынычы белән бәйле булмаган башка эшкә үз ризалыклары белән вакытлыча күчереләләр. Болай күчерү мөмкин булмаганда - баш дәүләт санитар табибләре һәм аларның урынбасарлары күрсәтмәсе буенча әлеге затлар, социаль иминләштерү пособиесе түләнгән килеш, вакытлыча эшләреннән азат ителәләр.

Кешегә яшәү тирәлеге факторларының уңайсыз йогынтысына бәйле йогышлы, йогышлы булмаган массакүләм авырулар (агуланулар) алар ачылган урындагы халыкның сәламәтлеген саклау һәм санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органнарында теркәлергә һәм дәүләт исәбенә алынырга, хисап алып барылырга тиеш.

Йогышлы һәм йогышлы булмаган массакүләм авыруларны (агулануларны) дәүләт исәбенә алуны кертү тәртибе, шулай ук алар буенча хисап бирү тәртибе халыкның сәламәтлеген саклау һәм санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы белән берлектә билгеләнә.

32 статья. Профилактик-медицина тикшерүләрен оештыру һәм уздыру

Исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан законнар нигезендә раслана торган аерым һөнәрләрнең, житештерүләрнең, оешмаларның хезмәткәрләре алдан мәжбүри (эшкә кергәндә) һәм аннан соң даими рәвештә (21 яшькә кадәрге затлар- ел саен) профилактик-медицина тикшерүләрен узалар.

Медицина тикшерүләрен узмаган хезмәткәрләр эшкә алынмый.

Житештерү процессына бәйле авыруларны профилактикалау максатларында уздырыла торган медицина тикшерүләре мәжбүри медицина иминләштерүенең нигези һәм территория программаларына кертелергә тиеш.

Профилактик-медицина тикшерүләре узу турындагы белешмәләр шәхси медицина кенәгәсенә кертелергә һәм халыкның сәламәтлеген саклау, санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органнарының учреждениеләре һәм оешмалары тарафыннан исәпкә алынырга тиеш.

Индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар хезмәткәрләрнең үз вакытында медицина тикшерүләрен узу өчен кирәкле шартлар тудырырга тиешләр.

33 статья. Профилактик прививкалар

Йогышлы авыруларның килеп чыгуын һәм таралуын булдырмау өчен гражданнарга законнар нигезендә профилактик прививкалар ясала.

34 статья. Гражданнарны гигиенага өйрәтү, аларга гигиена тәрбиясе һәм белеме бирү

Гражданнарны гигиенага өйрәтү, аларга гигиена тәрбиясе һәм белеме бирү укыту һәм тәрбия программаларына гигиена белемнәре турында бүлекләр кертү юлы белән түбәндәге процессларда башкарыла:

мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләрендә, югары һәм урта белем бирү йортларында тәрбияләү һәм укыту;

хезмәткәрләрне әзерләү, яңа һөнәргә өйрәтү һәм белгечлекләрен арттыру;

эшчәнлекләре зарарлы хезмәт шартларына, ашамлык продуктларын, азык-төлек чималын, эчәр суларны һәм халык кулланугындагы башка товарларны житештерүгә, саклауга, транспортлауга һәм реализацияләүгә бәйле оешмаларның урындагы затларын һәм хезмәткәрләрен һөнәри гигиеник әзерләү һәм (яисә) аттестацияләү, балаларны тәрбияләү һәм укыту, халыкка коммуналь, көнкүреш һәм медицина хезмәте күрсәтү.

35 статья. Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә житештерү һәм җәмәгать контролен башкару

Индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар эпидемиягә каршы санитар (профилактик) гамәлләрнең үтәлүенә, чыгарыла торган продукциянең, башкарылучы эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатына һәм куркынычсызлыгына житештерү контролен (тиешле норматив документларда каралган лаборатор күрсәткечләрне дә кертеп) тәэмин итәргә тиеш.

Гражданнарның иҗтимагый берләшмәләре үз уставлары нигезендә билгеләнгән санитар кагыйдәләрне үтәүгә җәмәгать контроле үткәрергә һәм аның нәтиҗәләре хакында халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органына хәбәр итәргә хокуклы.

VI бүлек. Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт идарәсе

36 статья. Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт идарәсе

Халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт идарәсе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты һәм халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы житәкләүче Татарстан

Республикасы дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте тарафыннан гамәлгә ашырыла.

37 статья. Дәүләт санитария-эпидемиология нормалаштыруы

Дәүләт санитария-эпидемиология нормалаштыруын Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәтләре бергәләп гамәлгә ашыралар.

38 статья. Эшчәнлекнең (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) кеше өчен потенциаль куркыныч булган аерым төрләрен лицензияләү үзенчәлекләре

Эшчәнлекнең (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) кеше өчен потенциаль куркыныч булган аерым төрләре законнар нигезендә лицензияләнергә тиеш.

Эшчәнлекнең (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) кеше өчен потенциаль куркыныч булган күрсәтелгән төрләренең санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитария-эпидемиология бәяләмәсен лицензия алырга теләүченең тапшыруы лицензия бирү турында карар кабул итү өчен мәҗбүри шарт була.

39 статья. Кеше өчен потенциаль куркыныч булган продукциянең, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләрен сертификацияләү үзенчәлекләре

Кеше өчен потенциаль куркыныч булган продукциянең, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләрен сертификацияләү, аларның санитар кагыйдәләр таләпләренә туры килүе турында гигиеник бәяләмәсе булганда гына, законар нигезендә гамәлгә ашырыла.

40 статья. Санитария-эпидемиология экспертизалары, тикшерүләре, тикшеренүләре, күзәтүләре, сынаулары, токсикологик, гигиеник һәм башка төрле бәяләүләр

Санитария-эпидемиология экспертизалары, тикшерүләре, тикшеренүләре, күзәтүләре, сынаулары, токсикологик, гигиеник һәм башка төрле бәяләүләр Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте органнары,учреждениеләре, билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнгән оешмалар һәм экспертлар тарафыннан расланган алымнарны, үлчәүләрне үтәү методикаларын һәм үлчәү чараларының типларын кулланып башкарыла.

Санитария-эпидемиология экспертизаларының, тикшеренүләренең, тикшерүләренең, сынауларының, токсикологик,

гигиеник бәяләүләрнең һәм билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән бүтән төрле бәяләүләрнең нәтиҗәләре нигезендә баш дәүләт санитария табибләре законнар нигезендә санитария-эпидемиология бәяләмәләре бирәләр.

Татарстан Республикасы дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте органнары һәм учреждениеләре, билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнгән оешмалар һәм санитария-эпидемиология экспертизаларын, тикшеренүләрен, тикшерүләрен, күзәтүләрен, сынауларын һәм токсикологик, гигиеник һәм башка төрле бәяләүләр бирүләрне уздыручы экспертлар аларның сыйфаты һәм объективлык өчен законнар нигезендә җаваплы булалар.

<u>41 статья.</u> Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеге

Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелегенә түбәндәгеләр керә:

санитар законнарның, эпидемиягә каршы санитар (профилактик) гамәлләрнең, санитария-эпидемиология күзәтчелеген башкаручы урындагы затлар чыгарган күрсәтмәләрнең һәм карарларның үтәлешен тикшереп тору;

санитар-карантин тикшереп тору;

халыкта йогышлы һәм йогышлы булмаган массакүләм авырулар (агуланулар) килеп чыгу һәм таралу сәбәпләрен һәм шартларын ачыклау һәм билгеләү;

санитар хокук бозуларны булдырмау чараларын күрү һәм хокук бозган затларны җаваплылыкка тарту;

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү гамәлләрен үткәрү буенча үтәлеше мәҗбүри тәкъдимнәр әзерләү;

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә статистик күзәтү алып бару, яшәү тирәлеге факторларының кешегә уңайсыз йогынты ясавына бәйле рәвештә халыкта йогышлы, һөнәри һәм йогышлы булмаган массакүләм авыруларның (агулануларның) дәүләт исәбен алып бару, шулай ук санитария-эпидемиология вәзгыяте турында мәгълүматлар банкын барлыкка китерү.

Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәтләре бергәләп гамәлгә ашыралар.

<u>42 статья.</u> Социаль-гигиеник мониторинг

Халыкның сәламәтлеге һәм яшәү тирәлеге торышын ачыклау, анализлау, бәяләү һәм фаразлау яисә яшәү тирәлегенең кешегә уңайсыз йогынтысын киметү максатларында Татарстан Республикасында социаль-гигиеник мониторинг алып барыла.

Татарстан Республикасында социаль-гигиеник мониторинг Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәтенең органнары һәм учреждениеләре тарафыннан дәүләт идарәсе органнары һәм җирле үзидарә органнары белән бергә башкарыла.

Татарстан Республикасы территориясендә социаль-гигиеник мониторинг алып бару тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

## VII бүлек. Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте

### 43 статья. Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәтен оештыру һәм аның системасы

Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү максатларында эшләүче органнарның һәм учреждениеләрнең бердәм системасы була.

Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте системасына түбәндәгеләр керә:

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы;

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органының республика үзәкләре һәм учреждениеләре;

районнарда, шәһәрләрдә, шәһәрләрдәге районнарда дәүләт санитария-эпидимиология күзәтчелеге үзәкләре;

дезинфекция станцияләре.

Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте системасы эшчәнлеген оештыруны Татарстан Республикасының баш дәүләт санитар табибе һәм аның урынбасарлары, шулай ук районнарның, шәһәрләрнең, шәһәрләрдәге районнарның баш дәүләт санитар табибләре һәм аларның урынбасарлары гамәлгә ашыралар.

Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте турындагы нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

### 44 статья. Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәтен финанс ягыннан тәэмин итү

Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәтен финанслау законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан

Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла.

Эпидемиягә каршы санитар (профилактик) гамәлләрне финанслауның өстәмә чыганаклары түбәндәгеләр булырга мөмкин:

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү һәм авыруларны профилактикалау өлкәсендәге федераль, республика һәм җирле программаларны гамәлгә ашыру өчен каралган федераль, республика һәм җирле бюджетларның акчалары;

эпидемиягә каршы санитар (профилактик) гамәлләрне финанслауга юнәлдерелгән республика һәм территория сырхауханә кассалары акчаларының бер өлеше;

Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте органнарына һәм учреждениеләренә китерелгән өстәмә зыяннарны түләттерү тәртибендә эпидемиягә каршы санитар (профилактик) гамәлләр уздыруга гражданнардан, индивидуаль эшкуарлардан һәм юридик затлардан алынган акчалар;

санитар хокук бозулар өчен штраф санкцияләреннән килгән һәм законнарда каралган тәртиптә бүленгән акчаларның бер өлеше;

Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте органнары һәм учреждениеләре тарафыннан законнар нигезендә шартнамә буенча эшләр башкарган һәм хезмәтләр күрсәткән өчен килгән акчалар;

юридик һәм физик затларның ирекле кертемнәре һәм иганәләре;

законнарда тыелмаган башка чыганаклар.

<u>45 статья.</u> Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте органнарының һәм учреждениеләренең мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән файдалану хокукы

Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте органнары һәм учреждениеләре үзләренә бирелгән бурычларны үтәү өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә кулланылучы биналар, урыннар, корылмалар, җайланмалар, транспорт чаралары һәм башка мөлкәт республика милкендә була һәм күрсәтелгән органнарга һәм учреждениеләргә хуҗалык итү һәм (яисә) оператив идарә хокукында законнарда билгеләнгән тәртиптә тапшырыла.

Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте органнарының һәм учреждениеләренең биналары һәм корылмалары урнашкан җир кишәрлекләре даими куллану өчен аларга законнарда билгеләнгән тәртиптә бушлай тапшырылалар.

46 статья. Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәтенең санитария-эпидемиология дәүләт күзәтчелеген башкарырга вәкаләтле урындагы затлары

Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәтенең санитария-эпидемиология дәүләт күзәтчелеген башкарырга вәкаләтле урындагы затларына түбәндәгеләр керә: Татарстан Республикасының баш дәүләт санитар табибе һәм аның урынбасарлары, районнарның, шәһәрләрнең, шәһәрләрдәге районнарның баш дәүләт санитар табибләре һәм аларның урынбасарлары, күрсәтелгән хезмәт органнарының һәм учреждениеләренең белгечләре.

Дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген башкарырга вәкаләтле белгечләрнең исемлеге Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте турындагы нигезләмәдә билгеләнә.

Дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген башкаручы урындагы затлар законнар нигезендә дәүләтнең махсус яклавында булалар.

Дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген башкаручы урындагы затларга аларның һөнәри вазыйфаларын үтәүгә комачауларлык теләсә-нинди йогынты яисә аларның эшчәнлегенә катышу тыела һәм законнар нигезендә җаваплылыкка китерә.

Баш дәүләт санитар табибләре һәм аларның урынбасарлары вазыйфаларын башкару хокукына югары медицина белеме алган һәм «медик-профилактик эш» белгечлеге буенча сертификаты булган затлар ия булалар.

47 статья. Дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген башкаручы урындагы затларның хокуклары

Дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген башкаручы урындагы затлар үзләренең хезмәт вазыйфаларын башкарганда һәм хезмәт таныклыгын күрсәткән килеш түбәндәге хокукларга ия булалар:

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча дәүләт идарәсе органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, индивидуаль эшкуарлардан һәм юридик затлардан документлаштырылган мәгълүмат алу;

санитария-эпидемиология тикшеренүләре уздыру;

дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелегенеке булган территорияләрдә һәм объектларда индивидуаль эшкуарларның һәм идарә итү вазыйфаларын коммерция яисә башка төрле оешмаларда башкаручы затларның, урындагы затларның санитар законнарны һәм күрсәтелгән объектларда эпидемиягә каршы санитар (профилактик)

гамәлләрне үтәүләрен тикшереп тору максатларында каршылыксыз булу;

гражданнарның торак шартларын карап тикшерү максатларында алар ризалыгы белән торак урыннарында булу;

продукциянең, шул исәптән азык-төлек чималының һәм ашамлык продуктларының пробаларын һәм үрнәкләрен тикшерү өчен аларны сайлап алу;

транспорт чараларының һәм аларда ташылучы йөкләрнең санитар кагыйдәләргә туры килү-килмәвен билгеләү максатларында, хокук саклау органнары белән берлектә, транспорт чараларын һәм аларда ташылучы йөкләрне, шул исәптән азык-төлек чималын һәм ашамлык продуктларын карап чыгу;

тикшеренүләр өчен һава, су һәм туфрак пробаларын сайлап алу;

яшәү тирәлеге факторларының санитар кагыйдәләргә туры килү-килмәвен билгеләү максатларында мондый факторларны үлчәү;

санитар законнарны бозу турында беркетмә төзү.

Санитар законнарны бозулар ачыкланганда, шулай ук йогышлы авырулар һәм йогышлы булмаган массакүләм авырулар (агуланулар) барлыкка килү һәм таралу янаганда дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген башкаручы урындагы затлар гражданнарга һәм юридик затларга билгеләнгән вакыт эчендә үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмәләрне түбәндәге мәсьәләләр буенча бирергә хокуклы:

ачыкланган санитар кагыйдәләрне бозуларны бетерү турында;

санитар кагыйдәләргә туры килмәгән яисә санитария-эпидемиология бәяләмәсе булмаган продукцияне, шул исәптән азык-төлек чималын һәм ашамлык продуктларын реализацияләүне туктату турында;

эпидемиягә каршы санитар (профилактик) өстәмә гамәлләр уздыру турында;

йогышлы авырулар белән аралашкан гражданнарны лаборатор тикшерү һәм мондый гражданнарга медицина күзәтүе уздыру турында;

йогышлы авырулар учакларында, шулай ук йогышлы авырулар килеп чыгарлык яисә таралырлык шартлар булган һәм сакланып калган территорияләрдә һәм биналарда дезинфекция, дезинсекция һәм дератизация эшләрен башкару турында.

**48 статья.** Баш дәүләт санитар табибләренең һәм аларның урынбасарларының вәкаләтләре

Баш дәүләт санитар табибләре һәм аларның урынбасарлары, әлеге Законның 47 статьясында каралган хокуклар белән бергә, түбәндәге вәкаләтләргә ия булалар:

1) санитар законнарны бозулар турындагы материалларны һәм эшләрне карау;

2) санитар законнар бозылган очракта судка һәм арбитраж судка дәгъвалар тапшыру;

3) гражданнарга, индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга санитария-эпидемиология бәяләмәләре бирү;

4) гражданнарга, индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга санитар законнарны бозулар буенча материалларны һәм эшләрне карау өчен аларны Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте органнарына һәм учреждениеләренә чакыру турында билгеләнгән вакытта үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү;

5) санитария-эпидемиология экспертизасы уздыру;

6) йогышлы авырулар һәм йогышлы булмаган массакүләм авырулар (агуланулар) барлыкка килү һәм таралу янарлык итеп санитар законнарны бозуларны ачыклау һәм мондый хокук бозуларны бетергәнче аларны туктатып тору турында яисә эшчәнлекнең түбәндәге төрләрен бетерү мөмкинлеге булмаганда аларны тыю турында билгеләнгән тәртиптә карарлар чыгару:

проектлау, төзелеш, реконструкцияләү, объектларны техник яктан коралландыру һәм аларны эксплуатациягә тапшыру;

объектларны, житештерү цехларын һәм участокларын, биналарны, корылмаларны, урыннарны, җайланмаларны, транспорт чараларын эксплатацияләү, кайбер эш төрләрен башкару һәм хезмәтләр күрсәтү;

продукцияне әзерләү, житештерү, реализацияләү һәм куллану (файдалану);

азык төлек-чималын, ашамлык өстәлмәләрен, ашамлык продуктларын, эчәр суларны һәм аларга орынып торучы материалларны һәм әйберләрне житештерү, саклау,транспортлау һәм реализацияләү;

эчәр сулар белән, хуҗалык-көнкүрешне су белән тәэмин итү өчен, коену, спорт белән шөгыльләнү, ял итү максатларында һәм дәвалау максатларында су объектларыннан файдалану;

санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитария-эпидемиология бәяләмәсе булмаган яисә законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлмәгән продукцияне, кеше өчен потенциаль зарарлы химик, биологик, радиоактив матдәләрне, продукциянең аерым төрләрен, калдыкларны, товарларны, йөкләрне Татарстан Республикасы территориясенә кертү;

7) әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудырырлык йогышлы авырулар барлыкка килү һәм таралу янаганда түбәндәгеләр турында карарлар чыгару:

тикшеренүләр уздыру өчен госпитализацияләү турында яисә тирә-юньдәгеләр өчен куркыныч тудырырлык йогышлы авыруларны һәм мондый авырулар кичерү шиге булганнарны изоляцияләү турында;

тирә-юньдәгеләр өчен куркыныч тудырырлык йогышлы чирдән авыручылар белән аралашкан гражданнарга мәҗбүри медицина каравын уздыру, аларны госпитализацияләү яисә изоляцияләү турында;

үзләрендә йогышлы авырулар китереп чыгаручыларны йөртүче һәм үзләре башкарган эш яисә җитештерү үзенчәлекләренә бәйле рәвештә йогышлы авыруларны тарату чыганагы булырлык затларны эшләреннән вакытлыча җибәреп тору турында;

эпидемик күрсәткечләр буенча гражданнарга яисә гражданнарның кайбер төркемнәренә профилактик прививкалар уздыру турында;

оешмаларда һәм объектларда чикләү гамәлләрен (карантин) кертү (юкка чыгару) турында;

8) санитар законнарны бозган өчен кисәтүләр яисә штрафлар рәвешендә административ җәза бирү турында карарлар чыгару;

9) продукция халыкның гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан-туры янаган очракларда җинаять эшләрен кузгату яисә мондый продукцияне конфискацияләү турында мәсьәләләрне хәл итү өчен санитар законнар бозу хакындагы материалларны хокук саклау органнарына җибәрү;

10) тәкъдимнәр кертү:

санитария-эпидемиология вәзгыятен яхшырту һәм санитар законнарның таләпләрен үтәү гамәлләрен тормышка ашыру турында, шулай ук территорияләрнең социаль-икътисадый үсеше программалары проектларына, халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү, сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча республика максатчыл программаларына кагылышлы тәкъдимнәрне - дәүләт идарәсе органнарына һәм җирле үзидарә органнарына;

чикләү гамәлләрен (карантин) кертү (юкка чыгару) турында - Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына һәм районнарның, шәһәрләрнең һәм шәһәрләрдәге районнарның җирле администрацияләренә;

алар кабул иткән карарларны, фәрманнарны, күрсәтмәләрне һәм билгеләмәләрне халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү мәсьәләләренә кагылышлы өлешләрендә санитар законнарга туры китерү турында - оешмаларга;

юридик һәм физик затлар биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны проектлау һәм төзү эшләрен башкарганда санитар кагыйдәләрне бозган һәм мондый эшләрне туктатып тору яисә туктату турындагы карарларны үтәмәгән очракта аларның операцияләрен туктатып тору хакында - финанс-кредит оешмаларына;

продукциянең, эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең санитар кагыйдәләргә туры килмәвен ачыклаган очракларда продукциянең, эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең туры килү сертификатларының гамәлдә булуын туктатып тору яисә аларны бөтенләй кире алу турында -сертификация органнарына;

эшчәнлекнең кайбер төрләрен башкарганда санитар кагыйдәләрнең бозылуы ачыкланган очракларда эшчәнлекнең кайбер төрләренә бирелгән лицензияләрнең гамәлдә булуын туктатып тору яисә бөтенләй кире алу турында - лицензия органнарына;

санитар кагыйдәләрне бозган хезмәткәрләргә карата дисциплинар җәза бирү турында - эш бирүчеләргә;

санитар законнарны бозу аркасында гражданга китерелгән зыянны түләттерү турында, шулай ук санитар законнарны шушы рәвешле бозу аркасында йогышлы авыруларны һәм йогышлы булмаган массакүләм авыруларны (агулануларны) бетерү гамәлләрен башкару өчен Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте органнарына һәм учреждениеләренә өстәмә китерелгән зыяннарны түләттерү турында - индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга.

**49 статья.** Татарстан Республикасының Баш дәүләт санитар табибе һәм аның урынбасарлары вәкаләтләре

Татарстан Республикасының Баш дәүләт санитар табибе, әлеге Законның 47 һәм 48 статьяларында каралган хокуклар һәм вәкаләтләр белән бергә, түбәндәгеләргә хокуклы:

дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары раслаган проектлауның проект нормаларының, проектларның республика стандартларының, төзелеш нормаларының һәм кагыйдәләренең, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау кагыйдәләре проектларының, мәгариф программаларының санитар законнарның таләпләренә туры килү-килмәве турындагы санитария-эпидемиология бәяләмәләрен бирергә, шулай ук әлеге документларны санитар законнарга туры китерү турындагы тәкъдимнәрне дәүләт идарәсе органнарына кертергә;

Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте ведомствосында булган органнарның һәм аларның хезмәткәрләренең эшчәнлеген регламентлаучы норматив һәм башка төрле документларны, шулай ук продукцияне һәм яшәү тирәлеге факторларын, кеше өчен имин һәм зарарсыз критерийлары буенча тикшеренүләрнең (сынауларның) ысулларын расларга.

**50 статья.** Дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген башкаручы урындагы затларның бурычлары

Дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген башкаручы урындагы затлар түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

санитар хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмый калу эшчәнлеген башкарырга;

проект документларын карарга һәм экспертизаларга, кайбер объектларны һәм оешмаларны карап тикшерергә, кеше сәламәтлеге өчен яшәү тирәлеге факторларының һәм тормыш эшчәнлеге шартларының хәвефлелеген бәяләү нәтиҗәләре буенча юридик һәм физик затларга бәяләмәләр бирергә;

эш урынындагы вазыйфаларын башкарганда үзләренә мәгълүм булган мәгълүматка карата дәүләти, табиблек һәм закон белән саклanучы башка төрле яшеренлекне үтәргә;

халыкның санитария-эпидемиология уңайлыгы мәсьәләләре буенча гражданнарның һәм юридик затларның мөрәҗәгатьләрен карарга һәм тиешле чаралар күрергә;

тиешле территориядәге санитария-эпидемиология вәзгыяте турында, халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү һәм санитар хокук бозуларны булдырмый калу буенча Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте органнары һәм учреждениеләре кабул иткән гамәлләр турында дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм халыкка хәбәр итәргә;

үз эшчәнлеген дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары һәм гражданнарның җәмәгать берләшмәләре белән килештереп алып барырга;

халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү һәм санитар законнарны үтәү мәсьәләләрендә гражданнарның җәмәгать берләшмәләренә ярдәм күрсәтергә.

51 статья. Дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген башкаручы урындагы затларның җаваплылыгы

Дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген башкаручы урындагы затлар үз вазыйфаларын тиешенчә башкармаган (бөтенләй башкармаган) өчен, шулай ук халыкның санитария-эпидемия иминлегенә янарлык фактларны һәм хәлләрне яшереп калган өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә җаваплы булалар.

52 статья. Дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген башкаручы урындагы затларның гамәлләренә шикаять белдерү

Дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген башкаручы урындагы затлар гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата югарырак органга яисә турыдан-туры судка шикаять белдерелергә мөмкин.

Әгәр шикаять белдерелүче гамәлләрнең үтәлеше суд карары белән туктатып торылмаган булса, шикаять белдерелүче гамәлләрне шикаять бирү генә туктатып тормый.

## VIII бүлек. Санитар законнарны бозган өчен җаваплылык

53 статья. Санитар законнарны бозган өчен җаваплылык

Гражданнар, индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар санитар законнарны бозган өчен законнар нигезендә җаваплы булалар.

## IX бүлек. Йомгак нигезләмәләр

54 статья. Халыкара шартнамәләр

Әгәр халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы төзегән халыкара шартнамәдә әлеге Законда билгеләнгәннән бүтәнрәк кагыйдәләр урнаштырылган булса, халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

55 статья. Әлеге Законны гамәлгә кертү турында

Әлеге Законны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2475